ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

"Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 20 февралендә
кабул ителде

1 статья

"Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2008, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның икенче абзацында "Кече Әтнә," сүзләреннән соң "Яңа Әтнә," сүзләрен өстәргә;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әтнә муниципаль районы"
муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

"Әтнә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**



Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

2(11) - 11(12)	- Марий Эл Республикасы
11(12) - 28(47)	- Арча муниципаль районы
28(47) - 2(11)	- Биектау муниципаль районы

"Әтнә муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

Карта-схемадагы №	Муниципаль берәмлек
1	Олы Әтнә авыл җирлеге
2	Олы Мәңгәр авыл җирлеге
3	Югары Сәрдә авыл җирлеге
4	Комыргуҗа авыл җирлеге
5	Күәм авыл җирлеге
6	Күлле Киме авыл җирлеге
7	Күңгәр авыл җирлеге
8	Кышлау авыл җирлеге
9	Түбән Бәрәскә авыл җирлеге
10	Түбән Көек авыл җирлеге
11	Яңа Шашы авыл җирлеге
12	Өҗем авыл җирлеге

".

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 6 марты
№ 9-ТРЗ